**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 25 сентябрь № 710

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 9 август, 553 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 17 февраль, 92 нче; 2014 ел, 31 май, 371 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 643 нче; 2014 ел, 1 декабрь, 936 нчы; 2015 ел, 26 март, 186 нчы, 2015 ел, 28 август, 626 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы халкының эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортында:

«Ярдәмче программалар исемлеге» юлында «2014 – 2015 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту» сүзләрен «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту» сүзләренә алмаштырырга;

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп финанслау күләмнәре | Программаны финанслауның гомуми күләме – 11 315 776,7 мең сум, шул исәптән җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы – 6 530 025,3 мең сум, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән – 4 785 751,4 мең сум:<br>(мең сум) |

| | Ел | Җәлеп итәргә планлаштырыла торган федераль бюджет акчасы | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы |
|---|---|---|---|
| | 2014 | 957 036,6 | 668 907,79 |
| | 2015 | 901 603,4 | 631 712,01 |
| | 2016 | 907 223,7 | 694 059,3 |
| | 2017 | 846 432,1 | 706 040,8 |
| | 2018 | 972 576,5 | 695 010,5 |
| | 2019 | 972 576,5 | 695 010,5 |
| | 2020 | 972 576,5 | 695 010,5 |
| | Барлыгы | 6 530 025,3 | 4 785 751,4»; |

«Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре» юлына түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«1 000 эшләүчегә исәпләгәндә, җитештерүдә зыян күргәннәр саны – 1 000 эшләүчегә 0,94 кешедән артмый;»;

Программаның II бүлегендә:

дүртенче абзацта «2015» саннарын «2020» саннарына алмаштырырга;

текстка түбәндәге эчтәлекле яңа егерме бишенче абзац өстәргә:

«1 000 эшләүчегә исәпләгәндә, җитештерүдә зыян күргәннәр саны – 1 000 эшләүчегә 0,94 кешедән артмый;»;

Программаның III бүлегендә:

икенче абзацта «11 292 626,7» саннарын «11 315 776,7» саннарына алмаштырырга;

дүртенче абзацта «4 762 601,4» саннарын «4 785 751,4» саннарына алмаштырырга;

V бүлекнең дүртенче абзацында «1,24» саннарын «0,94» саннарына алмаштырырга;

Программага 1 нче кушымтада:

«Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту» ярдәмче юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту | 2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту | 1 000 эшләүчегә исәпләгәндә, җитештерүдә зыян күргәннәр саны, кеше | 1,28 | 1,00 | 0,98 | 0,96 | 0,94 | 0,94 | 0,94 | 0,94»; |

Программага теркәлгән 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә;

Программаның «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту» ярдәмче программасында (алга таба – Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программа):

Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программа исемендә «2015» саннарын «2020» саннарына алмаштырырга;

Ярдәмче программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Паспорт

| | |
|---|---|
| Ярдәмче программа исеме | «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту» ярдәмче программасы (алга таба – Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программа)) |
| Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаның дәүләт заказчысы | Татарстан Республикасы Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы |
| Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаның максаты | Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри куркынычларын киметү максатларында хезмәт шартларын һәм аны саклауны яхшырту |
| Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаның бурычлары | Хезмәтне саклау белән дәүләт идарәсе системасын үстерү;<br>укытуның заманча технологияләре нигезендә хезмәтне саклау буенча хезмәткәрләрне өзлексез әзерләү;<br>хезмәтне саклауны мәгълүмати тәэмин итү һәм пропогандалау |
| Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаны тормышка ашыру вакытлары | 2014 – 2020 еллар |
| Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Хезмәтне саклау буенча ярдәмче програм-маны финанслау күләмнәре | Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаны Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслауның гомуми күләме 32 410,0 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>2014 ел – 4 630,0 мең сум;<br>2015 ел – 4 630,0 мең сум;<br>2016 ел – 4 630,0 мең сум;<br>2017 ел – 4 630,0 мең сум;<br>2018 ел – 4 630,0 мең сум;<br>2019 ел – 4 630,0 мең сум;<br>2020 ел – 4 630,0 мең сум |
| Хезмәтне саклау | Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программа чараларын |

| | |
|---|---|
| буенча ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелгән соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеген бәяләү күрсәткечләре | тормышка ашыру 2020 елга түбәндәгеләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:<br>хезмәтне саклау буенча чараларга чыгымнарны 1 кешегә исәпләгәндә 19 452 сумга кадәр арттырырга;<br>җитештерүдә зыян күргәннәр санын 1 000 эшләүчегә исәпләгәндә 0,94 кешегә кадәр киметергә;<br>хезмәтне саклау буенча уку узган җитәкчеләр һәм белгечләр күләмен 1 000 эшләүчегә исәпләгәндә 20,13 кешегә кадәр арттырырга» |

Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаның II бүлегендәге җиденче абзацта «2015» саннарын «2020» саннарына алмаштырырга;

Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаны финанслау Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган 32 410,0 мең сум күләмендә акча исәбеннән гамәлгә ашырылачак, шул исәптән:

2014 ел – 4 630,0 мең сум;
2015 ел – 4 630,0 мең сум;
2016 ел – 4 630,0 мең сум;
2017 ел – 4 630,0 мең сум;
2018 ел – 4 630,0 мең сум;
2019 ел – 4 630,0 мең сум;
2020 ел – 4 630,0 мең сум.

Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаның төп чаралары ресурслар белән тәэмин ителеше турында мәгълүмат аңарга кушымтада китерелгән.»;

Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программаның V бүлегендә:

дүртенче абзацта «10 464» саннарын «19 452» саннарына алмаштырырга;

бишенче абзацта «1,24» саннарын «0,94» саннарына алмаштырырга;

алтынчы абзацта «17,41» саннарын «20,13» саннарына алмаштырырга;

Хезмәтне саклау буенча ярдәмче программага теркәлгән кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы А.В.Песошин